**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
**ТУКАЙ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ**
**ИШТИРӘК АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**

# КАРАР

«22» сентябрь 2026 ел Иштирәк авылы №4

Иштирәк авыл җирлеге Башкарма комитетының 2021 елның 5 июлендәге 9 номерлы карары белән расланган (25.09.2024 № 8 карар редакциясендә) «Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы Иштирәк авыл җирлеге территориясендә беренчел хәрби исәпкә алуны оештыру һәм гамәлгә ашыру турында нигезләмә» гә үзгәрешләр кертү хакында

Иштирәк авыл җирлеге Башкарма комитетының 2021 елның 5 июлендәге 9 номерлы карары белән расланган (25.09.2024 № 8 карар редакциясендә) «Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы Иштирәк авыл җирлеге территориясендә беренчел хәрби исәпкә алуны оештыру һәм гамәлгә ашыру турында нигезләмә»гә Тукай районы прокуратурасының протестын карап, Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы Иштирәк авыл җирлеге Башкарма комитеты

**КАРАР БИРӘ:**

1. Иштирәк авыл җирлеге Башкарма комитетының 2021 елның 5 июлендәге 9 номерлы карары белән расланган (25.09.2024 № 16 карар редакциясендә) «Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы Иштирәк авыл җирлеге территориясендә беренчел хәрби исәпкә алуны оештыру һәм гамәлгә ашыру турында нигезләмә»гә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. 3.6 пунктын тулыландырырга һәм түбәндәге редакциядә бәян итәргә: «Оешмаларның вазыйфаи затлары һәм гражданнар тарафыннан хәрби исәпкә алу, мобилизацион әзерлек һәм мобилизация бурычларын үтәмәү очраклары турында ачыкланган көннән алып 10 эш көне эчендә Россия Федерациясе Оборона министрлыгы билгеләгән электрон формада, шул исәптән күчмә мәгълүмат туплагычта, хәрби комиссариатларга белешмәләр тапшырырга.».

1.2. 3.7 пунктын үзгәртергә һәм түбәндәге редакциядә бәян итәргә: «Беренчел хәрби исәпкә алу документларындагы белешмәләргә үз вакытында үзгәрешләр кертергә һәм 10 эш көне эчендә кертелгән үзгәрешләр турында Россия Федерациясе Оборона министрлыгы билгеләгән форма буенча Татарстан Республикасы Яр Чаллы шәһәре Комсомол районы һәм Тукай районы хәрби комиссариатына хәбәр итәргә.».

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы рәсми хокукый мәгълүмат порталында (https://pravo.tatarstan.ru), рәсми сайтта (https://tukay.tatarstan.ru) урнаштырырга.

3. Әлеге карар үтәлешен контрольдә тотуны үз җаваплылыгымда калдырам.

Башкарма комитет Җитәкчесе А.П. Васильева